РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.06.2024 № 475-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 06 мартындагы 381-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары, өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча һәркемгә ачык һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Саба районы прокуратурасының 2024 елның 08 маендагы протесты белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 06 мартындагы 381-п номерлы карарына һәм федераль законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары, өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 6 мартындагы 381-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль берәмлеге муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары, өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру турында нигезләмәне раслау хакында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

**1.1.** 2.3 пунктта «дәүләт аккредитациясе турында таныклык» сүзләрен «гамәлгә ашырыла торган мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясен бирү датасы һәм теркәү номеры турында белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

**1.2.** 3.1 пунктының өченче абзацында «яисә тиешле белем бирү программасы буенча дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булу срогы тәмамлану» сүзләрен «дәүләт аккредитациясе гамәлдә булуын туктату» сүзләренә алмаштырырга;

**1.3.** 3.1 пунктының дүртенче абзацында «, дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булуын тулысынча яисә белем бирүнең аерым дәрәҗәләренә, һөнәр, белгечлек һәм

әзерлек юнәлешләренең зур төркемнәренә карата гамәлдә булуын туктату» сүзләрен төшереп калдырырга;

**1.4.** 4.6 пунктта «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 8 апрелендәге 293 номерлы боерыгы» сүзләрен «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 15 маендагы 236 номерлы боерыгы» сүзләренә алмаштырырга;

**1.5.** 4.11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.11 Мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты һәм мәктәпкәчә белем бирүнең тиешле федераль белем бирү программасы нигезендә, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан эшләнә һәм раслана. Мәгариф оешмалары тарафыннан эшләнгән белем бирү программаларының эчтәлеге һәм планлаштырылган нәтиҗәләре федераль мәктәпкәчә белем бирү программасының тиешле эчтәлегеннән һәм планлаштырылган нәтиҗәләреннән түбән булмаска тиеш.»;

**1.6.** 6.7 пунктына «әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса» сүзләрен өстәргә;

**1.7.** 7.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.2. Өстәмә гомуми үсеш программаларының эчтәлеге һәм алар буенча уку вакыты белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан эшләнгән һәм расланган белем бирү программасы белән билгеләнә. Сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри программаларның эчтәлеге федераль дәүләт таләпләренә ярашлы рәвештә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан эшләнгән һәм расланган белем бирү программасы белән билгеләнә. Спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларының эчтәлеге спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын исәпкә алып, спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан эшләнгән һәм расланган тиешле белем бирү программасы белән билгеләнә.»;

**1.8.** 7.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.7. Өстәмә гомуми белем бирү программалары учреждение тарафыннан мөстәкыйль рәвештә дә, аларны гамәлгә ашыруның челтәр формалары аша да гамәлгә ашырыла. Өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 11 октябрендәге 1678 номерлы карары белән расланган Белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны, электрон укытуны, дистанцион белем бирү технологияләрен куллану кагыйдәләре таләпләрен исәпкә алып, төрле белем бирү технологияләре, шул исәптән дистанцион белем бирү технологияләре, электрон укыту кулланыла.»;

**2.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми рәвештә игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru.

Башкарма комитет Җитәкчесе вазифаларын башкаручы,
Башкарма комитет Җитәкчесенең
икътисад буенча – Саба муниципаль районы
икътисад бүлеге башлыгы М. М. Баһманов